**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 ноябрь № 884

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 12 октябрь, 715 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 12 октябрь, 715 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 29 июль, 603 нче, 2010 ел, 1 октябрь, 779 нчы, 2011 ел, 13 май, 382 нче, 2012 ел, 8 июнь, 494 нчең, 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2012 ел, 3 ноябрь, 948 нче, 2013 ел, 8 апрель, 239 нчы, 2014 ел, 9 август, 599 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр (алга таба – лицензия) рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү белән бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан башкарыла.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын алуга аукцион (алга таба – аукцион) үткәрмичә генә бирелгән очракларда, гариза Вәкаләтле органга бирүче аукцион үткәрмичә генә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алуга әлеге тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә заявка (алга таба – заявка) һәм «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган документларны тапшыра»;

2.2 һәм 2.3 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Заявканы һәм барлык кирәкле документларны алган көннән соң 20 эш көненнән артмаган вакытта Вәкаләтле орган гариза бирүчегә җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү турында яки мондый хокукны бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә, бу хакта тиешле карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә гариза бирүчегә хәбәр итә. Бу чакта җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә гариза бирүчегә, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, язма рәвештә җибәрелә (тапшырыла).»;

2.6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2.9 пунктта «лицензия килешүе» сүзләренә кадәр «җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында (шартнамә)» сүзләрен өстәргә;

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү турында карар чыгарылган көннән соң 20 эш көне эчендә гариза бирүчегә имза кую өчен җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензия килешүе (шартнамә) проекты бирелә.»;

2.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11. Аукцион нәтиҗәләре буенча лицензия Вәкаләтле орган тарафыннан аукцион җиңүчесенә рәсмиләштерелә. Вәкаләтле орган аукцион нәтиҗәләре расланган көннән соң 30 көн эчендә аукцион җиңүчесенә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү турында карар кабул итә, шулай ук аңарга имза кую өчен җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензия килешүе (шартнамә) проектын җибәрә.»;

2.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Лицензия һәм җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензия килешүе (шартнамә) гариза бирүче яки аукцион җиңүчесе имзалаган җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензия килешүе (шартнамә) проекты кергән көннән соң өч эш көне эчендә Вәкаләтле орган житәкчесе тарафыннан имзалана.

Әгәр гариза бирүче яки аукцион җиңүчесе җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензия килешүе (шартнамә) проектын алган көннән соң 30 көн эчендә әлеге документның имзаланган проектын Вәкаләтле органга тапшырмаса, Вәкаләтле орган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү турында карарны гамәлдән чыгару хакында карар кабул итә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.12[1] пункт өстәргә:

«2.12[1]. Лицензиядәге техник хаталарны төзәтү «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3.4 пунктның дүртенче абзацында «барлык каты файдалы казылмалар,» сүзләреннән соң «В – җир асты сулары,» сүзләрен, «Э – эксплуатацияләнүче» сүзләреннән соң «(разведкалау һәм чыгару)» сүзләрен өстәргә;

3.9 пунктта «теркәлгән лицензияләр» сүзләрен «җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү турында карарлар» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны 3.11 пункт дип санарга;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштергән өчен дәүләт пошлинасын түләү турында документ.»;

4.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга яңадан рәсмиләштерелә торган лицензиянең барлык кушымталары булган төп нөсхәсе.»;

4.9 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек өстәргә:

«5. Дәүләт пошлинасы

5.1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензия биргән, лицензия барлыгын раслый торган документны яңадан рәсмиләштергән, лицензия дубликатын биргән (тапшырган) яисә лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайткан өчен дәүләт пошлинасы алына.

5.2. Алынган дәүләт пошлинасының вакыты һәм зурлыгы салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.»;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә);

әлеге Тәртипкә 8 нче кушымтада 11 – 46 пунктларын тиешенчә 10 – 45 пунктлар дип санарга;

әлеге Тәртипкә 9 нчы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибенә 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 ноябрь, 884 нче карары редакциясендә)

Форма

Оешма бланкы

Татарстан Республикасы экология
һәм табигый байлыклар министрына
_______________________________
Ф.И.Ә.и.

Аукцион үткәрмичә генә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын алуга заявка

_______________________________________________________________________________
җир асты байлыклары кишәрлеге (чыганак) исеме

1.гариза бирүче _________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
юридик зат исеме, вазыйфасы, җитәкче Ф.И.Ат.ис.

2. Дәүләт теркәвенә алу кодлары һәм реквизитлары: ______________________________
ИНН,
_______________________________________________________________________________
ОГРН, ОКПО, ОКОНХ, ОКПО, ОКОГУ, БИК, ОКАТО, ОКВЭД һ.б.
_______________________________________________________________________________

3. Юридик адресы: _______________________________________________________________
Почта адресы: __________________________________________________________________
телефон: (код) ________________________, телефакс:(код) __________________
e-mail(булганда): _________________________________________________________
4. Гариза бирүченең эшмәкәрлек максаты, күздә тотылган эшләр исемлеге:
_______________________________________________________________________________
җир асты байлыкларыннан файдалану максатлары, файдалы казылманың төре күрсәтелә
_______________________________________________________________________________,
гомумтаралган файдалы казылмалар исемлеге нигезендә

эшләрне үткәрү вакытлары: ______________________________________________________
_______________________________________________________________________________

5. Банк реквизитлары: ___________________________________________________________
исәп-хисап счетлары номерлары,
_______________________________________________________________________________
банклар исемнәре

6. Теркәлгән документлар исемлеге:
1) ______________________________
2) ______________________________
3) ______________________________
…) ______________________________
)

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Предприятие җитәкчесе: _____________________________________________
имза, Ф.И.Ат.ис. М.У.

_______________________________________

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр рәсмиләштерү, янадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибенә 9 нчы кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 ноябрь, 884 нче карары редакциясендә)

Форма

## Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр реестры

| Т/с | Теркәүгә алу датасы | Лицензиянең теркәү саны | | | Лицензия хуҗасы, урнашу адресы | Максатчан билгеләнеше һәм эшләр төре | Лицензия бирелгән җир асты байлыклары кишәрлеге | | Лицензиянең гамәлдә булу вакыты тәмамлану | Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы барлыкка килү турында карар | Лицензине теркәгән зат имзасы | махсус билгеләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | серия-се | саны | төре | | | объект төре, урнашу урыны (муниципаль район, якындагы торак пунктларның берсе) | бүлеп бирү статусы | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |